ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25 март 2021ел № 2051

Башкарма комитетның 2019 елның 29 июлендәге 3864 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю урынын (мәйданчыгын) булдыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю урынын (мәйданчыгын) булдыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 29 июлендәге 3864 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю урынын (мәйданчыгын) булдыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.4 пунктның 5 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

2) 2.14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү һәм аларның көтеп тору урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә | 1) муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган бүлмәләрдә һәм биналарда гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 12 пункты; «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен уңайлылыгын тәэмин итүгә, андый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга таләпләр | мөмкинлекләрен истә тотып урнаштырыла.<br>2) инвалидларга тәэмин ителә:<br>- муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бинага, бүлмәгә тоткарлыксыз керү (керү һәм аннан чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып);<br>- муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарда, бүлмәләрдә, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналар, бүлмәләр урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;<br>- күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе бозылган инвалидларны озатып йөрү һәм аларга муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарда, бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;<br>- инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, бүлмәләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөрткечләрне тиешенчә урнаштыру;<br>- ишетә һәм күрә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны рельефлы-нокталы Брайль шрифтында башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;<br>- закон нигезендә билгеләнә торган форма буенча һәм тәртиптә бирелә һәм махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булганда, муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, бүлмәләргә юл күрсәтүче этне кертү;<br>- муниципаль хезмәт күрсәтә торган оешмаларның хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә муниципаль хезмәттән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.<br>Әлеге пунктның 2 пунктчасында | Федераль законның 15 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| | күрсәтелгән таләпләр бары тик файдалануга яңа тапшырылган яки реконструкцияләнгән, модернизацияләнгән объектларга һәм чараларга гына куела. | |

3) 3.1.2 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

4) 3.4.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар законда билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.»;

5) 3.5.1-3.5.2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.1. Бүлек белгече гамәлгә ашыра:

1) гаризага теркәлгән документлардагы мәгълүматларны һәм ведомствоара запрос буенча алынган документларны (мәгълүматны) тикшерүне;

2) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләр булуны тикшерүне;

3) проект әзерләүне:

- әлеге регламентка 5 нче кушымтада каралган форма буенча, ККК җыю урынын (мәйданчыгын) булдыруны килештерү турында Башкарма комитет карары (алга таба – карар проекты) (муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта);

- ККК җыю урынын (мәйданчыгын) булдыруны килештерүдән баш тарту турында белдерү кәгазе (алга таба – белдерү кәгазе проекты) (муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләр булган очракта);

4) карар проектын яки белдерү кәгазе проектын килештерү өчен район хакимияте Башлыгы урынбасарына җибәрүне.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерү өчен район хакимияте Башлыгы урынбасарына җибәрелгән карар яки белдерү кәгазе проекты.

3.5.2. Район хакимияте Башлыгы урынбасары карар проектын яки белдерү кәгазе проектын карап тикшерә, килештерә һәм килештерү өчен район хакимияте Башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар карар проекты яки белдерү кәгазе проекты кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерү өчен район хакимияте Башлыгына җибәрелгән карар проекты яки белдерү кәгазе проекты.»;

6) 1.5.3-1.5.5 пунктларны 3.5.3-3.5.5 пунктлар дип санарга һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.3. Район хакимияте Башлыгы карап тикшерә:

- карар проектын, килештерә һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә;

- белдерү кәгазе проектын, килештерә һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура карар проекты яки белдерү кәгазе проекты кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерелгән һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән карар проекты яки килештерелгән һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына җибәрелгән белдерү кәгазе проекты.

3.5.4. Башкарма комитет Җитәкчесе карар проектын карап тикшерә, имзалый һәм теркәү өчен эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан

башлап бер календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган һәм теркәү өчен эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән карар проекты.

3.5.5. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гамәлгә ашыра:

1) имзаланган карар проектын Башкарма комитет карарларын теркәү журналында теркәүне;

2) тарату реестры нигезендә Башкарма комитетның теркәлгән карары күчермәләрен бирүне.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура имзаланган карар проекты эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән һәм тарату реестры нигезендә бирелгән Башкарма комитет карары күчермәләре.»;

7) түбәндәге эчтәлектәге 3.5.6, 3.5.7 пунктлар өстәргә:

«3.5.6. Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары белдерү кәгазе проектын карап тикшерә, имзалый һәм аны теркәү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган, теркәү өчен җибәрелгән белдерү кәгазе.

3.5.7. Белдерү кәгазен теркәү Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарының чыгу корреспонденциясе журналында гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура имзаланган белдерү кәгазе кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән белдерү кәгазе»;

8) 2 нче кушымта үз көчен югалткан дип танырга;

9) 3 нче кушымтада «Башкарма комитет Җитәкчесе» сүзләрен «Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары» сүзләренә алмаштырырга;

10) кушымтада каралганча 5 нче кушымта өстәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет » челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Комсомол районы хакимияте Башлыгы А.И. Кисловка, Үзәк районы хакимияте Башлыгы И.Н. Галимовка, Автозавод районы хакимияте Башлыгы В.Х. Харисовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 25 мартындагы
2051 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю урынын (мәйданчыгын) булдыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
5 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю урынын (мәйданчыгын) булдыруны килештерү турында

__________________________________________ гаризаны караганнан соң, Башкарма комитетның ____ елның ____________ ______ номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю урынын (мәйданчыгын) булдыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. _________________________________ адресы буенча урнашкан каты коммуналь калдыкларны җыю урынын (мәйданчыгын) булдыруны кушымтада каралганча килештерергә.

2. Башкарма комитетның _____________ районы хакимиятенә кабул ителгән карар турында гариза бирүчегә хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Ф.И.А.и., ____________ районы хакимияте Башлыгы Ф.И.А.и. йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Башкарма комитетның
20__ елның «___» _________
____ номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре территориясендә
каты коммуналь калдыкларны җыю урынының (мәйданчыгының) урнашу схемасы

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе
урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе
башлыгы вазыйфаларын башкаручы А.Ф. Бареева